# *“Тезмә кушма җөмлә”* темасы буенча 8 нче сыйныф өчен тест

1. ***Алсу яшеннән бик курыкты һәм өй эченә кереп китте.***

- **Бу гади җөмлә.**
- **Бу кушма җөмлә.**
- **Бу сүзтезмә.**

# 2.Җөмләләр арасыннан тезмә кушма җөмләне табыгыз:

- Тиз йөгереп килгәнгә, аның хәле беткән иде.
- Чынаяк өстәлдән төшеп китте дә ватылды.
- Урманда хәзер гөмбәләр бардыр, ахры.
- Бераздан салкын җил исте дә яңгыр яварга тотынды.

# 3. Бирелгән җөмләләр арасыннан теркәгечле тезмә кушма җөмләне табыгыз:

- Такта янына чыккач, ул аптырап калды.
- Мин шәһәргә бардым, ләкин сине күрмәдем.
- Бүген көн матур, ләкин салкын җил исә.
- Сания алдан китте, Гөлшат аның артыннан йөгерде.

# 4. Бирелгән җөмләләр арасыннан теркәгечсез тезмә кушма җөмләне табыгыз:

- Такта янына чыккач, ул аптырап калды.
- Мин шәһәргә бардым, ләкин сине күрмәдем.
- Бүген көн матур, ләкин салкын җил исә.
- Сания алдан китте, Гөлшат аның артыннан йөгерде.

## 5. Бирелгән җөмләнең грамматик нигезен билгеләгез:

***Самат кулына матур туп тоткан, аның янында бер бәләкәй генә көчек йөри.***

- **Туп тоткан; Самат йөгереп йөри**
- **Туп тоткан; көчек йөри**
- **Самат тоткан, йөри**
- **Самат тоткан; көчек йөри**

# 6. Кайсы җөмләдә тыныш билгесе дөрес куелмаган:

- Көз җитте һәм яфраклар коела башлады.
- Мин аны чакырдым – ул килмәде.
- Җәйләр үтте, салкын көзләр җитте.
- Бераздан Илгиз арыды һәм Динар эшкә кереште.

# 7. Кайсы җөмләдә тыныш билгесе дөрес куелган:

- Кыз өенә кайтып керде дә, әбисенә елмайды.
- Әсәр укылды, инша язылды.
- Агачта чыпчык утыра ә бер бала аңа карап тора.
- Бакчада алмагач бар ул инде картайган алма бирми.